Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Урман- Көләй авыл җирлегенең
Колшәрип тимер юл станциясе бистәсе гражданнар җыены нәтиҗәләре
турындагы карары

6 декабрь 2023 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2023 елның 05 декабрендә 10 сәгать 00 минутта булган гражданнарның җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге: «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман-Көләй авыл җирлеге Колшәрип тимер юл станциясе бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме:торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләүгә ризамы?» соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 16 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 11 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 9 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 2 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман- Көләй авыл җирлегенең Колшәрип тимер юл станциясе бистәсе гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман- Көләй авыл җирлеге Колшәрип тимер юл станциясе бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләүгә ризамы?» турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Колшәрип тимер юл станциясе бистәсе , Железнодорожная урамы, территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман- Көләй авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Урман- Көләй авыл җирлеге башлыгы Л.Н. Фәләхиев